# ЯМЬЛЕ ЧАК

Җәй уртасы - *ямьле чак*,
Чәчәкле җәймә - болын.
Күбәләктәй кыз бала
Канаттай җилпи кулын.

Ак тасма чәчләрендә,
Ак күлмәк өсләрендә,
Җүреп-җүреп чигелгән
Чәчәк бар түшләрендә.

Киң елмая күк йөзе,
Кояш та кыса күзен.
Бөтен дөнья таң калган,
Онытып әйтер сүзен.

Күбәләк тә күбәләк,
Кыз бала да - күбәләк,
Чәчәкләр җыеп йөри,
Бер басып, бер чүгәләп.

Карап тора әнисе,
Карап тора әтисе.
Табигать язган әсәр -
Күңелдә мәңге яшәр!